| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**20.12.2017 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3218** |

Пиротехник эшләнмәләр куллану урынын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге «Пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм файдаланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» 1052 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2017 елның 14 декабрендәге 989 номерлы карары, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2017 елның 21 ноябрендәге 47/32 номерлы күрсәтмәсе нигезендә һәм Яңа ел бәйрәме чараларының, гражданнар гомере һәм сәламәтлегенең, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең, дәүләт мөлкәтенең яки муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә пиротехника әйберләрен имин куллану максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәрендә пиротехник эшләнмәләр куллану өчен «Мирный» микрорайонында, Төзүчеләр урамында, «Мәйдан»да урыннар билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлекләре Башлыкларына һәм Башкарма комитетлары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

һәр торак пунктта пиротехник эшләнмәләр куллану өчен урыннар билгеләү эшен дәвам итәргә, аларны Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге белән килештерергә, пиротехник эшләнмәләр куллану урыннарын мәгълүмат стендлары һәм янгын сүндерү чаралары белән җиһазландырырга, тиешле карарлар чыгарырга. Пиротехник эшләнмәләр куллану урыннарын фотоматериаллар белән чыгарылган карарларның күчермәләрен Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге карамагына тапшырырга;

пиротехник эшләнмәләр куллану урыннарын сайлаганда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге «Пиротехник әйберләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында»1052 номерлы карары һәм «Пиротехник эшләнмәләрнең куркынычсызлыгы турында» 2011 елның 16 августындагы 770 номерлы таможня союзының техник регламентына таянырга;

2010 елның 12 гыйнварындагы «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезләмәләрен исәпкә алып, пиротехник эшләнмәләр куллану урыннары турында мәгълүматны халыкка җиткерергә.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 1052 номерлы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Пиротехник әйберләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау хакында» 2017 елның 14 декабрендәге 989 номерлы карары нигезендә «ЗМР ТКХ департаменты» МБУ җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.В. Благовещенскийга, «Коммуналь хуҗалык» МУП директоры А.И. Нигъмәтуллинга «Мирный» микрорайонына пиротехник эшләнмәләр куллану өчен урыннарны җиһазлау эшен оештырырга .

4. Пиротехника кулланып тамаша уздырганда (КСК «Авангард», башлану - 22.00) «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 8 нче отряды» федераль дәүләт казна учреждениесе башлыгы З.М. Хәлиуллинга, ТР буенча Россия ГТХМ күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге башлыгы Р.Р. Ардыхановка иминлекне тәэмин итәргә, Зеленодольск муниципаль районының авыл (шәһәр) җирлекләре башлыкларына һәм Башкарма комитетлары җитәкчеләренә пиротехник эшләнмәләр куллану өчен урыннар җиһазлау буенча методик ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Интернет челтәрендә хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ЗМР Башкарма комитеты җитәкчесе А.Х.Сәхибуллин